ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.11.2023 с.Старое Дрожжаное №457

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын эшләү турында

Территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү, әйләнә-тирә мохитне саклау, территорияләрне планлаштыру өчен шартлар тудыру, физик һәм юридик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8 статьясындагы 1 пунктына, 30, 31, 32 статьяларына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14, 15 статьяларына, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 31 декабрендәге 507-ФЗ номерлы Федераль законына, Россия Федерациясе Икътисади үсеш министрлыгының 2018 елның 09 гыйнварындагы 10 номерлы боерыгына таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын эшләүгә керешергә.
2. 1 нче кушымта нигезендә шәһәр төзелешен зоналаштыру этапларын билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү буенча эшләрнең тәртибен һәм срокларын расларга (2 нче кушымта).
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) вакыттан үз көченә керә.
5. Әлеге карарны «Туган як» район газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Чүпрәле муниципаль районының (https://droganoye.tatarstan.ru) рәсми сайтына

урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары Р.Р. Багаутдиновка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.И. Мөхәммәтҗанов

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның "16" ноябрендә 457 номерлы карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын әзерләгәндә шәһәр төзелешен зоналаштыру этаплары**

1 нче этап - территориянең гамәлдәге хәленә анализ ясау, территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналарда билгеләнгән җир кишәрлекләренең чикләрен (саклау, санитария-яклау зоналары, минималь ераклыктагы зоналар, санитария шартлаулары, су саклау зоналары, эчәр сулар белән тәэмин итү чыганакларының санитария саклау зоналары), җирлекне үстерү программаларын исәпкә алып, башлангыч мәгълүматларны җыю;

2 нче этап - җирлек территориясендә булган һәм планлаштырыла торган җирле, республика һәм федераль әһәмияттәге объектларны анализлау;

3 нче этап - территориаль зоналарның чикләрен формалаштыру буенча тәкъдимнәр әзерләү.

Эшләр идарәчесе: Д.Р. Сабирзянова

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның "16" ноябрендә 457 номерлы карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре (алга таба – ПЗЗ) проектын әзерләү буенча эшләрнең тәртибе һәм вакыты**

| № п/п | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен әзерләү буенча эшләр үткәрү тәртибе | Эшләрне үткәрү вакыты | Башкаручы, җаваплы зат |
|---|---|---|---|
| 1 | ПЗЗ проектын әзерләү турында Карар кабул итү | 2023 елның ноябре | Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) |
| 2 | ПЗЗ проектын әзерләү турында карарны бастырып чыгару | Кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә | Башкарма комитет |
| 3 | Физик һәм юридик затлардан ПЗЗ проекты буенча тәкъдимнәр кабул итү | ПЗЗ проектын әзерләү турында карар басылып чыкканнан соң бер ай эчендә | Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы җирдән файдалану һәм авыл җирлекләрендә төзелеш кагыйдәләре проектларын әзерләү буенча Комиссия (алга таба-Комиссия) |
| 4 | ПЗЗ проектын әзерләү буенча эшләр үткәрү | Подряд шартнамәсе нигезендә | Комиссия |
| 5 | ПЗЗ проектын тикшерү үткәрүне техник регламентларның, җирлекне, муниципаль районны, Татарстан Республикасын, Россия Федерациясен территориаль планлаштыру документларының туры килүенә тәэмин итү | 7 көн дәвамында | Башкарма комитет |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6 | Түбән Чәке авыл җирлеге башлыгы экспозиция өчен ПЗЗ проектын һәм материалларны җибәрү | Тикшерү нәтиҗәләре буенча уңай килешүдән соң 5 көн эчендә | Комиссия |
| 7 | ПЗЗ проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында Карар кабул итү | ПЗЗ проектын алганнан соң 10 көн эчендә | Түбән Чәке авыл җирлеге башлыгы |
| 8 | Гавами тыңлауларын үткәрү турында карарны бастырып чыгару | Кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә | Түбән Чәке авыл җирлеге башлыгы |
| 9 | ПЗЗ проекты материаллары экспозициясен ачу | 7 нче этап тәмамланганнан соң 2 көн эчендә | Түбән Чәке авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| 10 | ПЗЗ проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү | 8 нче этап тәмамланганнан соң бер айдан артык түгел | Түбән Чәке авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| 11 | Гавами тыңлаулар беркетмәсен әзерләүне тәэмин итү һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәләр бастырып чыгару | Гавами тыңлаулары уздырылганнан соң 10 көн эчендә | Түбән Чәке авыл җирлеге башлыгы, Комиссия |
| 12 | Башкарма комитетка гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча ПЗЗ проектын, протоколны һәм нәтиҗәләрне әзерләү һәм җибәрү | 2 көн дәвамында | Комиссия |
| 13 | ПЗЗ проектын Чүпрәле муниципаль районы Советына җибәрү | 5 көн дәвамында | Башкарма комитет |
| 14 | Чүпрәле муниципаль районы Советы тарафыннан ПЗЗ проекты буенча карар кабул итү | Чүпрәле муниципаль районы Советының чираттагы сессиясендә | Чүпрәле муниципаль районы Советы |
| 15 | ПЗЗ проекты буенча карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгару | Кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә | Чүпрәле муниципаль районы Советы |

Эшләр идарәчесе: Д.Р. Сабирзянова